**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АЛЬКЕЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**

**РЕШЕНИЕ** Базарлы Матак **КАРАР**

2022 елның 15 августы 122№

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советының 2016 елның 15 декабрендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында нигезләмә хакында» 73 номерлы карарына үзгәреш кертү турында

2021 елның 2 июлендәге "Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 352-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы "Әлки муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Әлки муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. атарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советының 2016 елның 15 декабрендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында нигезләмә хакында» 73 номерлы карарына (яңа 2019.25.10, 266№, 2017.15.11, 133№ редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 бүлекнең 3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

"3. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планына (программасына) кертелгән унитар предприятиеләр, акционер җәмгыятьләр һәм җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр 2011 елның 6 декабрендәге «Бухгалтерлык исәбе турында» 402-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясында (алга таба - бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгының дәүләт мәгълүмат ресурсы) каралган бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгының дәүләт мәгълүмат ресурсын формалаштыру максатында отчет бирү бурычыннан азат ителгән очракта, “Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы” муниципаль казна учреждениесенә бухгалтерлык хисабы турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән срокта еллык бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгының мәҗбүри нөсхәсен, квартал, яртыеллык, тугыз ай өчен арадаш бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгы хисап чоры тәмамланган көннән

алып утыз көн эчендә соңга калмыйча арадаш бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын, күрсәтелгән хисаплылыктагы мәгълүматны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://alkeevskiy.tatarstan.ru/. веб-адресына урнаштырып тапшыра. Күрсәтелгән предприятиеләр һәм җәмгыять бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгының дәүләт мәгълүмат ресурсын формалаштыру максатларында еллык бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын күрсәткән очракта, «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып, әлеге дәүләт мәгълүмат ресурсыннан шундый хисап ала.

2. Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (htth:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әлки район Советының Законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Әлки муниципаль районы Башлыгы: А. Ф. Никошин